АРБОР ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ

# “КУРКЫНЫЧСЫЗ ТӘГӘРМӘЧ”

УЕНЫ ӨЧЕН

АГИТБРИГАДА ЧЫГЫШЫ

Төзеде: Мифтахова Р.Б.

2021

Катнаша: Яшь юл инспекторларының махсус киемнәрен кигән 4 бала.

Тезелеп басалар һәм сөйлиләр:

1. Исәнмесез, дуслар,
   Малайлар һәм кызлар!
   Сезне сәламлибез
   Яшь ЮИД чы без!
2. Бездән нәни бер дустыбыз
   Сорый икән әгәр:
   Юлда нәрсә яхшы диеп,
   Ә нәрсәсе – хәтәр?
3. Без аңлатып бирик шундук
   Кечкенә булсак та
   ЮХИДИ абыйлар кебек
   Торабыз сакта.
4. Юллар озын, юллар төрле
   Юллар куркыныч.
   Шул юлларда дөрес йөрү –
   Безнең зур бурыч.
5. Хәвефсез булсын дисәгез
   Йөрисе юллар,
   Кагыйдәне төгәл итеп
   Үтәгез, дуслар!
6. Юллар озын, юллар кызык,
   Юллар тыныч булсын,
   Моның өчен һәрбер бала
   Кагыйдәне белсен!
7. Җәяүлеме, шофермы син,
   Әллә сәпиттә?!
   Юлларда уяу булырга
   Кирәк, әлбәттә!
8. Кечкенәдән өйрәнергә
   Тырыш барысын.
   Шул чагында сау-сәламәт
   Имин калырсың!

Җыр: “Бәхетле булыгыз” көенә җырлыйлар.

Әгәр син юл кагыйдәсен
Өйрәнсәң әйбәт:
Юлда йөрүләр – сөенеч,
Юлларда - рәхәт!

Кушымта:
Һәммәгез дә безнең
Теләктән уңыгыз:
Гел матур, хәвефсез
Уң булсын юлыгыз!

Тиешсез урыннан чыкма,
Игътибарлы бул!
Тәртипсезләрне беркайчан
Гафу итми юл!

Кушымта:
Һәммәгез дә безнең
Теләктән уңыгыз:
Гел матур, хәвефсез
Уң булсын юлыгыз!

Машина юлыннан йөрмә
Җәяүле булсаң,
Светофорны кара башта
Кайсы күз янган!?

Кушымта:
Һәммәгез дә безнең
Теләктән уңыгыз:
Гел матур, хәвефсез
Уң булсын юлыгыз!

Зур бәйрәм быел сезнең
Котлап китәбез,
Сезнең сафка үзебез дә
Үсеп җитәрбез.

Без бит сезнең ярдәмчеләр,
Без - уң кулыгыз!
Һәрчак имин һәм хәвефсез
Булсын юлыбыз!

85 яшь ЮХИДИга,
Ә без – унбердә!
Сәламәтлек, иминлекне
Саклыйк без бергә!

Сүз бирәбез: үрнәк булыр
Тәртип бозмавыбыз,
Ихластан кабул итегез
Сезне котлавыбыз!

(Төрле юл билгеләрен тезеп куеп):

Иминлек, тынычлык сакчысы Сез (билге – ЮХИДИ хезмәткәре)

Кайгыртып һәр кеше турында . (билге – балалар)

Начарга һәрвакыт юк диясез (билге – кирпич)

85 ел юллар сагында! (билге -85 дип язган)

(шарлар чөяләр)

Тәмам.